**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.08.2018 Балык Бистәсе штп. № 188пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү мәсьәләләре һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча эшче төркем турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча чаралар белән оператив идарә итү максатларында, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнары башкарма комитетлары һәм шәһәр округлары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре катнашында 2018 елның 5 июлендә үткән “түгәрәк өстәл” утырышының Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллин тарафыннан 2018 елның 17 июлендә расланган РН-12-198 номерлы беркетмәсенең 1.4 пунктының беренче абзацын үтәү йөзеннән,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү мәсьәләләре һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча эшче төркем төзергә (алга таба – эшче төркем).

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү мәсьәләләре һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча эшче төркем турында Нигезләмәне һәм аның составын расларга (Нигезләмә һәм эшче төркем составының исемлеге теркәлә).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Таҗетдинов

Татарстан РеспубликасыБалык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 8 августындагы
188пи номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү мәсьәләләре һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча эшче төркем турында**
**Нигезләмә**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү мәсьәләләре һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем),җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнары башкарма комитетларыһәм шәһәр округлары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре катнашында 2018 елның 5 июлендә үткән “түгәрәк өстәл” утырышының Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллин тарафыннан 2018 елның 17 июлендә расланган РН-12-198 номерлы беркетмәсенең 1.4 пунктының беренче абзацын үтәү йөзеннән,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендәҗир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләүһәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру белән бәйле мәсьәләләрне оператив һәм нәтиҗәле хәл итү максатларында төзелә.

2.Эшче төркем Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

3.Эшче төркем үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, муниципаль норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4.Эшче төркем әгъзалары үзләренең эшчәнлекләрен түләүсез гамәлгә ашыралар.

5.Эшче төркемнең төп бурычлары булып тора:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләрендә һәм Балык Бистәсе штп.даҗир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләүһәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча тирәнтен тикшереп тәкъдимнәр эшләү,бәяләү һәманализлау;

жир асты суларын казып чыгару максаты белән жир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү, шулай укТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләрендә һәм Балык Бистәсе штп.дасу чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү.

6.Эшче төркем түбәндәге хокукларга ия:

үзенең утырышларында, компетенциясенә кергән мәсьәләләрне карап, алар буенча карарлар кабул итү;

билгеләнгән тәртиптә эше өчен зарур булган статистик һәм информацион материаллар алу;

законда билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларын үтәү өчен кирәкле материал һәм мәгълүматларны соратып алдыру;

башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның вәкилләренэшче төркемнең утырышларына чакыру һәм үз компетенциясендәге мәсьәләләр буенча аларның һәм эшче төркем әгъзаларының хәбәрләрен тыңлау.

7.Эшче төркем үз эшчәнлеген коллегиаль нигездә гамәлгә ашыра.

8.Эшче төркем утырышын үткәрү турында карар эшче төркемнең җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.Эшче төркем җитәкчесенең карары буенча утырышта киңәшләшү хокукына ия тавыш белән төркем составына кермәгән затлар катнаша ала.

9.Эшче төркемнең утырышлары аның җитәкчесе тарафыннан оештырыла, ә ул юкта – эшче төркем җитәкчесе урынбасары тарафыннан, утырышлар зарур булган саен үздырыла, әмма кварталга бер мәртәбәдән дә ким түгел, һәм утырыш аның эшендә эшче төркем составының яртысыннан артыгы катнашканда вәкаләтле санала.

10.Эшче төркемнең карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыныңэшче төркем составында үзләренең вәкилләре дә булганҗирле үзидарә органнары өчен мәҗбүри төстә,башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм оешмалар өчен киңәш бирү төсендә була.

Эшче төркем утырышының беркетмәсе эшче төркем җитәкчесе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана һәм кул куелган көннән алып календарь көннәрдә саналган өч көн эчендә эшче төркемнең барлык әгъзалары адресына җибәрелә.

11.Эшче төркем эшчәнлегенең оештыру-техник тәэмин ителешен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма

комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге гамәлгә ашыра.

Татарстан РеспубликасыБалык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 8 августындагы
188пи номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җир асты суларын казып чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү мәсьәләләре һәм су чыганакларын санитар саклау зоналары оештыру буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Ризаев Дамир Наилович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Хәсәнов Рәүф Ногманович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетыныңтөзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы, эшче төркемнең сәркатибе |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Рәшитов Роберт Рәфыйкович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыМөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе(килештерү буенча) |
| Миличихина Ирина Львовна | Роспотребнадзор Идарәсенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарында ТБ башлыгы урынбасары (килештерү буенча) |
| Мифтахов Альберт Равилевич | “Балык Бистәсе торак-коммуналь сервисы” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры(килештерү буенча) |
| Магизов Марс Венерович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты |

житәкчесе(килештерү буенча)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килештерү буенча)(җир асты байлыкларының һәм су чыганакларының кайсы территориядә булуы буенча).